In recent years one of the most successful authors in Tatar literature in Bashkortostan has been Khisametdin Ismagilov. Every single piece of writing from this author, who has been living in a small village in the Starlebash Region working as a vet his entire life, is incredibly captivating and mesmerizing. Regardless of the genre, all of his works have something in common, that is a rich and exciting storyline.

The way the heroes’ lives drastically change in a matter of seconds creates a sense of adventure. For instance, in “Qalimchi Jäüdät” (“Jaudat the Tinker”) the main character Jaudat travels to Afganistan and Uzbekistan, in “Saq-Soq” (“Saq and Soq”) Faizulla finds himself in Tadjikistan, another unnamed character goes to Sakhalin and all the way to Japan. The life of the main character in “Su anasi” (“Water Spirit”) changes unexpectedly even from his trip to a neighbouring village. The causes of these changes, though not too big, draw the readers in by their mysteriousness. The author’s short novels “Faizulla”, “Qalimchi Jäüdät” (“Jaudat the Tinker”) focus on characters living in foreign lands, and in case of the story “Yavuray”, facing different challenges of the world. These pieces raise such dreadful issues as drug and alcohol addiction and integrate them into beautiful love stories. But, notably, the love stories told by Kh. Ismagilov are not ordinary; the author conveys love and feelings with incredible poetism (“Su anasi” (“Water Spirit”)). His short novel “Zimaghular” (“The Seasonal Workers”) tells a story of Basurman and Mansur who escape the gold mine. “The author gives the readers a close look at the lives of these runaways who, having cheated death, struggle with all their being to break free and consequently experience suffering to unfathomable levels” [Kashfi, p. 181].

In his writing style, Kh. Ismagilov also takes inspiration from Oriental literature and uses elements of folklore. So, while some of his works are written in the form of a story within a story, the other are reminiscent of a fairytale, an anecdote or a tale. In some cases, the narrator does not directly participate in the events of the story, but only stands as an observer. “When looking for modern interpretation of Oriental literary traditions and elements of folklore (legends, fairytales, epics, anecdotes) in works of modern authors, one can easily find it in the works of Khisametdin Ismagilov” [Khaliullina, 2013, p. 189]. A single central character, all of the twists and turns of the storyline, unexpected situations, action and adventure, the framed composition of his works – all of these originate from the folklore traditions.

Since the very first literary endeavors Dilbar Bulatova has established her own personal style. Her first piece of writing “Bügen bezdä korän ashi” (“Today We Have a Quran Ash”, 1993) regarding her personal feelings and experiences possesses qualities of the blank verse genre. The inner rhythm and musicality of the prose lines give the piece a sense of compositional integrity. This genre is also evident in her other early works “Zängär küldä öch torna” (“Three Cranes on the Blue Lake”), “Külmäk” (“The Shirt”) and later work “Qunaq munchasi” (“The Guest Bathing House”). One her strongest suits is her ability to capture nature in the most vivid and unique way. Inspired by such prominent Tatar authors as G. Ibragimov, Sh. Kamal and M. Amir, her works not only unfold human relationships, but also glorify nature, show the connection between human and nature, human lives in harmony with nature, “capture the contradiction inside the literary hero through symbolism, metaphors and other literary descriptive devices” [Yusupov, Gilazov, p. 346].

In our view, the way D. Bulatova shows the world from an unexpected angle distinguishes her from any other writer. “Her stories bring up simple, at first sight, experiences of human life and draw attention to the impact they have on the person. The events and experiences are not extreme and quite common, yet they have an immense impact on the characters” [Khaliullina, Collecting Stars into a Bucket, 2011, p. 36]. Having found

themselves in an unfamiliar and unusual to them environment, the characters open up in a new and unexpected, even for themselves, way. 'For instance, in "Lift" ("The Lift") the characters find themselves isolated from the surrounding world in a broken lift and after a while put their pride aside and open up to each other. The lift here acts as symbolic image of an opportunity for them to get on a new level of mental and emotional state.

D. Bulatova's story "Külmäk" ("The Shirt") centers around a village and cruel ideas of capitalism that start making their way into the village's life and raises the issues of morality. During the Sabantuy Rashit climbs up the post no one was able to climb up before him and looks over the square. This very episode shows how beautiful the simple, or even poor, countrymen, who barely managed to make some money thanks to the Sabantuy celebrations, are inside. But, as people belong to the earthly world, this world has its laws. When Rashit comes down to the ground, he becomes just a small person, disappears in the crowd; he buys a cheap pair of children sandals for a present and rushes to get out of the square. He puts on his old 'shirt' and continues to live his simple ordinary life. This character also goes through the 'growing up' phase; Nazhip, his feisty and smart classmate, quickly proves Rashit's naivety and simple-heartedness. In "Qoye" ("The Well"), the characters, on the contrary, move downwards, to the earth. Here, the image of the well is not only a source of drinking water, but also a philosophical well of wisdom and experience. Just like in order to get to the life-giving pure water, you need to dig down deep through many layers of soil and rock, you can find an internal source of faith, kindness and wisdom deep inside your own soul. But every character has their own path towards finding this source (Balbalay, the boy), while some of them give it up just when they almost get there (the character of the father).

In the stories of D. Bulatova the central character at some point makes a transition to a whole new spiritual level: he feels confused, conflicted, guilty as he experiences a strong emotional stress, which changes his live and him as a person, and even seems to change the flow of time. At the culmination of the story his spirit grows wings which raise him over the mundanity of life and allow him to look at the past, the present and the future from a distance. Rahina ("Onyq" – "The Grandchild"), Rashit ("Külmäk" – "The Shirt"), Zubarzhat ("Zängär küldä öch torna" – "Three Cranes on the Blue Lake"), the Boy ("Qoye" – "The Well"), Farit and Farida ("Lift" – "The Lift"), the Guy ("Saqchy" – "The Guard") – they all learn their lessons through some critical situations in their lives, regarding which the author suggests the idea that these painful experiences would save them from making the same mistakes in the future.

For the author, perfect ideal characters are wise, experienced, patient, balanced people living in harmony with the world and themselves: the character of Mother (as Maryam in "Komandirovka" ("The Business Trip"), Grandmother in "Qunaq munchasi" ("The Guest Bathing House")), the old man Riza ("Riza"). Unlike other characters mentioned above, these heroes have a philosophical perspective on the abovementioned critical situations (meeting a nosey journalist ("Komandirovka", "Riza"), losing a house ("Qunaq munchasi"). This peculiarity of her stories can be explained by the spirituality of the author herself, as she lives in accordance with the canons of Islam and Sharia. In her work "Riza" the author touches on the philosophical issue of life and death, which came from the Tatar literature of the 20$^{th}$ century, and "suggests the idea regarding the value of life on earth" [Gilazov, p. 207].

In order to increase the effect of the messages in her stories, D. Bulatova uses different methods. For instance, in "Achiq isheklär köne" ("Doors Open Day") the fire brings Zubayer the feeling of apathy and pessimism, whereas in "Qunaq munchasi" ("The Guest Bathing House") it comes to the old lady as a test of life. The image of water given in different interpretations generally bears the meaning of cleansing, deliverance and gaining wisdom. In "Zängär küldä öch torna" ("Three Cranes on the Blue Lake") and "Qoye" ("The Well"), it comes in the form of a lake and a well, respectively, in "Qunaq munchasi" ("The Guest Bathing House") in the form of snowbanks, in "Tui" ("The Wedding") in the form of a spring etc. Just like water does not lose its properties when turned into snow, ice and steam, the majority of characters essentially stay true to themselves, which allows them to be hopeful about their future. Titles of the stories are generally given with a single 'key' word encasing the full complexity of the piece. As seen, the stories focus not on the character's relations to the external world, but on their inner conflict; the author uses methods of psychologism, includes internal monologues and implements the principles of realism. Yet, the range of emotions is not too intense, the colours are not too bright, but rather very subtle, reminiscent of natural earthy colours.

The first short novel by D. Bulatova, who has previously specialised in short stories, called "Jantöyäk" ("Sweetheart", 2010), we believe, combines all the above mentioned features in one literary piece [Khaliullina, 2013, p. 236]. All of the emotional struggles and aesthetic ideals talked about by the author from the very early works are creatively captured in the characters of Ghalia and Tahir. "The character of Ghalia embodies all the qualities of a traditional Turkic woman previously portrayed by such classics as Galimzhan Ibragimov. These qualities are optimism, incredible patience, sensibility, courage and love for life" [Kashfi, pp. 292-293]. Her short novel "Kötärmen, digän ideng…" ("You Said You Would Wait," 2017) raises the issues of humanity, love and hatred.

Aidar Zakiev is one of the youngest Tatar authors in Bashkortostan at the moment. Yet, from the very early period he never shied away from taking new directions with his comprehensive and productive work. His collected volume published under the name "Keshelär ilendä" ("In the World of People") has already caught attention of the general public and many literary critics. "In the World of People" by A. Zakiev is nothing less than an experiment towards modernization of the national prose' [Khafizov, p. 4] – the critic S. Khafizov wrote. M. Kabirov rates the works of his fellow writer as follows: "Aidar does not want to copy anyone, he is trying to find his own path, his own style. There is no one in the Tatar literature you can compare him to" [Kabirov, p. 20].

Stories that develop so dynamically, yet end with a cliffhanger, not only leave room for growth and development of the characters, but also leave space for the readers to digest and make their own conclusions. The author often reveals his characters from the point of their psychological types. Demanding of the society, of the people around them and on themselves, these characters, who are not afraid to go against the flow, are forced to go through difficult challenges, but still remain loyal to their wish to find harmony and peace. "He does not shy away from the truth. There is no sugarcoating. He always tries to capture the world as it is. So, more often than not, such straightforwardness naturally fills his works with bleak colours" [Suleymanov, 2014, p. 49]. The way the author uses different time frames in a single story, mythological materials in some of his works, the way he layers the storyline, and even includes naturalistic details allow the readers to interpret the stories in different ways, which shows the intellectual side of his work.

Bashkortostan is also home for many talented Tatar authors working in the genres of comedy and satire. There are satire books published by Rauf Khakimov ("Kemneng bürege jiliraq?" – "Whose Fur Hat Is Warmer?", 2004), Rashit Fazli ("Taraqan kharap itte" – "Ruined By Cockroaches", 2005), Rif Mukhammatov ("Buidaqlar jiyelishi" – "The Bachelors Meeting", 1994), Zanif Sayetov ("Bizäkle qorshau" – "Embellished Chains", 1997), Insur Musannif ("Ozaq yäshäü sere" – "The Secret of Longevity", 1999), Rais Riyan ("Ghalämät" – "The Sign", 2010). The social satire so masterfully showcased in the works of M. Saltykov-Shchedrin, A. Chekhov and others alike find its ground in the prose of Z. Akbarov. Kamil Fazlyi and Gabdulla Vafin have also proven themselves as talented satire prose writers. The short novel "Mäyetlär tirlämi" (2012) has rightfully took the work of G. Vafin to the next level [Khaliullina, 2012].

All in all, the stories and short novels of the authors mentioned above touch upon the whole spectrum of human issues: from social issues and human relationships to personal development, morality and fate. At the same time, it is important to point out the rarity of such literary genres as detective and romantic novels and almost nonexistence of other genres, such as science fiction and fantasy [Khaliullina, Suleimanova, 2015, p. 11]. But there is no denying the potential of new contemporary authors like Aidar Basirov, Aida Khairetdinova, Göl Mirhadi, Elmira Ibragimova, Dilya Mukharramova and Venera Mazhitova.

This brief review of the work of numerous Tatar authors from Bashkortostan who belong to different generations and write in different literary styles, vividly demonstrates their value not only within the local literature but on the scale of the whole Tatar literature as well. The works of Tatar prose from different parts of the country, being similar in many ways, still have their own tendencies and characteristics. They are notable contributions to the development of Tatar literature and capable of standing the test of time. And while the veterans of Tatar literature continue to work hard and create new masterpieces, the new generation of authors is sure to be able to continue the tradition and take their own place in the literary scene.

**References**

*Ədəbiat beleme: terminnar həm təshenchələr syzlege* (2007) [Literary Studies: A Dictionary of Terms and Concepts]. 231 p. Kazan, Mägarif. (In Tatar)

Atnabaev, A. (2003). "Ia rodilsia na svet, chtoby ukrasit' iego" ["I Was Born to This World to Brighten

It”]. Sovremenniki o narodnom poete. Sostav. R. Khannanov. 269 p. Ufa, Kitap. (In Russian)

Fatkheramov, R. (2004). *Tatarga satma matbugat* [Don’t Sell Printed Media to Tatars]. Kazan utlary. No. 3, pp. 142–149. (In Tatar)

Fazlutdinov, I. K. (2016). *Tənkyit'tə Bashkortstandagy həzerge tatar poeztiase* [Modern Tatar Poetry of Bashkortostan through Criticism]. Tatarica. No. 2 (7), pp. 64–78. (In Tatar)

Gilazov, T. Sh. (2015). *Vklad Dzhamala Validi v istoriiu tatarskoi literaturnoi mysli* [The Contribution of Jamal Validi to the History of Tatar Literary Thought]. Philology and culture. No. 4 (42), pp. 206–209. (In Russian)

Iusupov, A. V., Gilazov T. Sh. (2016). The Critic Jahmal Validi in the Context of Literary, Theoretical and Philosophical Searches of the Beginning of the 20th Century Literature. Journal of Language and Literature, ISSN: 2078– 0303, Vol. 7. No. 2. May, pp. 344–347. (In English)

Iuzmukhametova, L. N. (2016). *Novye iavlenia v tatarskoi proze rubezha XX– XXI vekov: postmodernizm* [New Phenomena in Tatar Prose at the Turn of the 20th Century: Postmodernism]. 220 p. Kazan, Kazan University Publishing House. (In Russian)

Kabirov, M. (2009). *Ədəbijatybyz bəhetenə bulsyn* [Here’s to the Future of Our Literature]. Tulpar. No. 6, pp. 20–21. (In Tatar)

Karim Qara. (2009). *Bez ənkəi iərəgennən chyktyk. Povest'lar, hikəialər* [We All Came From Our Mothers’ Hearts. Short Novels, Short Stories]. 304 p. Ufa, Kitap. (In Tatar)

Kashfi, L. (2014). *“Kizil Tang” həm zaman ədəbijaty* [“Kizil Tang” and Contemporary Literature]. 296 p. Ufa, ‘Qizil Tang’ Printing House. (In Tatar)

Khafizov, S. (2007). *Shagyjr'lekkə dəg#va ityləre Hodai belən tiңləү үzeңne: iash'lər prozasynda nilər bar?* [Claiming to Be a Poet is Like Comparing yourself to God: What Is Young Prose?] Kizil Tang. November, 15. (In Tatar)

Khafizov, S. (2010). *Avyl jash'ləre turynda zamancha əsər* [A Modern Story about Rural Youth]. Kizil Tang. November, 3. (In Tatar)

Khaliullina, A. G. (2016). *Regional'nye osobennosti sovremennoj tatarskoj prozy Bashkortostana* [Regional Features of Modern Tatar Prose in Bashkortostan]. Nacional'naia literatura respublik Povolzh'ia: problemy mezhkul'turnoi kommunikatsii: materialy Mezhregional'noi nauchno-prakticheskoi konferentsii (Kazan', 21–22 noiabria 2016 goda). Pp. 157–161. Kazan, izd-vo Kazan. un-ta. (In Tatar)

Khaiullina, A., Suleimanova, D. (2013). *Tugan iak ədiplərе. Bashkortstanda həzerge tatar prozasy: shəhes, iҗat, tənkyit'* [National Writers. Modern Tatar Prose in Bashkortostan: Personal Background, Work, Criticism]. 320 p. Ufa, Kitap. (In Tatar)

Khaliullina A., Suleimanova, D. (2015). *Ilham alyp tugan tufraktan* [Inspired by Their Native Land]. Tulpar. No. 4, pp. 28 – 31. (In Tatar)

Khaliullina, A. (2016). *Һər zamannyң үz җyry* [Every Period Has Its Own Song]. Balkish. Tөz. D. D. Suleymanova, A.G. Khaliullina. Pp. 6 – 33. Ufa, Mir Pechati. (In Tatar)

Khaliullina A. (2009). *Hikəia nidən gyibarət?* [What Makes a Story?] Tulpar. No. 1, pp. 34–36. (In Tatar)

Khaliullina, A. G. (2007). *Zaman həm geroi (həzerge tatar prozasynda ədəbi geroiny gəydələnderү məs'ələlərе). Monografia.* [Heroes of the New Age (On the Embodiment of Literary Heroes in Modern Tatar Literature). A Monograph]. 206 p. Ufa, BSPU Publishing House. (In Tatar)

Khaliullina, A. (2011). *M. Kəbirov povest'larynda aforistik fiker bireleshe* [Aphoristic Thought in the Short Novels of M. Kabirov]. Sistema nepryryvnogo obrazovania: shkola-pedkolledzh-vuz. Materialy regional'noi nauchno-prakticheskoi konferentsii, posviashhennoi 125-letiu so dnia rozhdenia G. Tukaia (Ufa, 21 aprelia 2011 g.). Pp. 154–156. Ufa, BSPU Publishing House. (In Tatar)

Khaliullina, A. (2011). *K. Kara prozasynda tөp motivlar* [The Main Motifs in the Prose of K. Qara]. Materialy Mezhdunarodnoi nauchno-prakticheskoi konferentsii, priurochennoi k 180-letiu so dnia rozhdenia M. Akmully. (Ufa, 16 dekabria 2011 g.). Pp. 260–264. Ufa, BSPU Publishing House. (In Tatar)

Khaliullina, A. (2013). *Maҗçaraly iulnyң hikməte* [The Philosophy of Adventure]. Ismagilov Kh. *Zimaghular* [The Seasonal Workers: A Short Novel]. Pp. 3–6. Ufa, Kitap. (In Tatar)

Khaliullina, A. (2011). *Chiləkkə ioldyz җyep (Dilbər Bulatova hikəialərendə geroi evoliutsiiase)* [Collecting Stars into a Bucket (the Evolution of the Main Character in the Stories of Dilbar Bulatova)]. Tulpar. No. 1, pp. 36–37. (In Tatar)

Khaliullina, A. (2012). . *Babajchylyk səbəplərе nidə?* [What Are the Reasons for the Reign of Grandfathers?]. Tulpar. No. 5, pp. 28 –29. (In Tatar)

Latyifi, F. (2003). *2002 nche el prozasyna ber karash* [The Year of 2002 in Prose]. Kazan utlary. No. 5, pp. 135 –140. (In Tatar)

Mingnullin, R. (2006). *“Bashkortstanda үzgə ber kөchle tatar ədəbiaty үsep kilə”* [“Bashkortostan is Raising a Strong Tatar Literary Community”]. Kizil Tang. December, 7. (In Tatar)

Morzakieva, D. (2012). *Milli Kitap: Zainap Biisheva ismendege Bashkortostan “Kitap” nəshriatynda milli basmalar nesherləү həm bredə dənia kyrən kitaplar hakında* [A National Book: Regarding National Publications and Books Published in the Zainap Biisheva Publishing House ‘Kitab’ in Bashkortostan]. 152 p. Ufa. (In Tatar)

Safuanov, S. (2006). *Rukhi küperlär* [Spiritual Bridges]. 376 p. Ufa, Kitap. (In Tatar)

Sagidullina, L. (2004). *Sary iortlar sere (M. Kəbirovnyң “Sary jortlar sere” əsərenə ber karash)* [The Secret of Yellow Houses (Review of ‘Sari yortlar sere’ (The Secret of Yellow Houses) by M. Kabirov)]. Tulpar. No. 1, pp. 48–50. (In Tatar)

Suleimanov, R. (2014). *Keshelər ilendə nilər bar?* [What is There in the World of People?] Bashkortostan ukutiusihi. No. 4, pp. 49–53. (In Tatar)

Suleimanov, R. (2011). *Bashkortstan tatar prozasynda kyrys realizm chalymnary* [Gritty Realism in Tatar prose of Bashkortostan]. Gumanisticheskoe nasledie prosvetitelei v kul'ture i obrazovanii: materialy Mezhdunarodnoi nauchno-prakticheskoi konferentsii, priurochennoi k 180-letiu so dnia rozhdenia M. Akmully, 16 dekabria 2011 g. Pp. 235– 241. Ufa. (In Tatar)

Zahidullina, D. F. (2006). *Tatar ədəbiaty: Teoria. Tarih.* [Tatar Literature: Theory. History]. D. F. Zahidullina, A. M. Zakirҗanov, T. Sh.Gyilaҗev, N. M. Iosypova. 319 p. Kazan, Məgarif. (In Tatar)

Zahidullina, D. (2010). *Jash'lərdə iaңalyk bar! (“Idel” zhurnalynda dən'ia kyrgən iash' iҗatchylarnyң əsərlərenə ber karash)* [The Youth Brings Innovation! (Review of the Works of Young Authors Published in The Idel Magazine). Idel. No. 12, pp. 54–57. (In Tatar)

Zahidullina, D. (2006). *Iaңa dulkynda (1980–2000 ellar tatar prozasynda tradicijalər həm jaңachalyk)* [The New Wave (Traditions and Novelties in the Tatar Prose of the 1980s–2000s)]. Pp. 169–179. Kazan, Mägarif. (In Tatar)

Zahidullina, D. (2004). *Uңai geroi iugalu: səbəplər, nətiҗələr* [The Loss of the Protagonist: Reasons and Results]. Kazan utlary. No. 10, pp. 134–144. (In Tatar)

---

# БАШКОРТСТАНДАГЫ ХӘЗЕРГЕ ТАТАР ПРОЗАСЫ: ӘДӘБИ БАРЫШ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

**Альбина Габит кызы Хәлиуллина,**
М.Акмулла исем. Башкорт дәүләт педагогия университеты,
Россия, 450000, Уфа ш., Октябрь революциясе ур., 3 нче А йорт,
ahmali76@mail.ru.

Мәкаләдә Башкортстандагы хәзерге татар прозасына, ягъни XX гасыр ахыры – XXI гасыр башы аралыгындагы чәчмә әсәрләргә гомуми күзәтү ясала, чорның әдәби процесс үзенчәлекләре ачыклана. Тулы бер тарихи чор кысаларында Башкортстан җирлегендәге хәзерге прозаның идея-тематик, әдәби-эстетик ягын ачыклау, жанр хасиятләрен, стиль тенденцияләрен өйрәнү омтылышы хезмәтнең яңалыгын билгели. Мәкаләдә чынбарлыкны чагылдыруда, тормыштагы катлаулы күренешләрне бар тулылыгында тасвирлауда, реалистик кануннар белән бергә, яңа стиль үзгәрешләре, әлегәчә күренмәгән сыйфатларның да әдәбиятта урын алуы хакында фикер йөртелә. Әдәби тәнкыйть тарафыннан хәзерге вакытка кадәр тиешенчә бәяләнмәгән кайбер авторларның әсәрләре дә игътибар үзәгенә алына. Язучыларның татар прозасына алып килгән яңалыгын, әдәби форма һәм композиция өлкәсендәге эзләнүләрен ачыклау максатыннан, Т. Таһиров, С. Поварисов, А. Магазов, Р. Сабитов, Р. Ханнанов, Э. Әгъзами, М. Гыйләҗев, И. Тимерханов, Ш. Исмәгыйлева әдәби эшчәнлекләренең төп сыйфатлары билгеләнә; Г. Гатауллин, Х. Мөдәрисова, Д. Булгакова, З. Салихова, А. Зәкиев кебек язучыларның кыскача иҗат портреты тәкъдим ителә; М. Кәбиров, К. Кара, Х. Исмәгыйлев, Д. Булатова прозасына шактый җентекле анализ ясала. Автор тарафыннан Башкортстандагы татар язучыларының иҗаты, төбәк әдәбияты кысаларында гына калмыйча, гомумтатар сүз сәнгате казанышы буларак та каралырга хаклы дигән фикер үткәрелә.

**Төп төшенчәләр**: хәзерге татар прозасы, Башкортстан, төбәк әдәбияты, әдәби барыш, традиция, яңачалык, жанр үзгәрешләре, синкретизм.

Татар әдәбияты тарихында Башкортстан туфрагында туып-үскән иҗатчыларның аерым урын алып торуы, сүз сәнгатенең үсешенә өлеш кертүе бәхәссез. Бәрәкәтле Башкортстан җире биргән йөздән артык язучы арасыннан Галимҗан Ибраһимов, Мирсәй Әмир, Әмирхан Еники, Нурихан Фәттах, Хәсән Сәрьян, Әхсән Баянов, Галимҗан Гыйльманов һ.б. иҗатлары, татар прозасының алтын хәзинәсен тулыландырып, аны баетып кына калмадылар, ә яңа биеклеккә күтәрүгә дә хезмәт иттеләр. «Башкортстанның үзендә яшәп иҗат итүче шагыйрьләр һәм проза осталары да бөтен татар әдәби хәзинәсенә сизелерлек байлык өстиләр» [Сафуанов, б. 13], – дип яза әдәбият галиме С. Сафуанов.

Үткән гасырның 80–90 елларындагы иҗтимагый-сәяси үзгәрешләр нәтиҗәсендә Башкортстандагы татар әдәбияты яңадан көчәеп китте. Татарстанның халык шагыйре Роберт Миңнуллин бер әңгәмәсендә, Башкортстан җирлегендә татар әдәбиятының

милли сүз сәнгате әдәби барышына сизелерлек йогынты ясавына басым ясап, болай дигән иде: «Башкортстанда үзгә бер көчле татар әдәбияты үсеп килә» [Миңнуллин, б. 5]. Чыннан да, соңгы елларда проза, яңа сулыш алып, сан һәм сыйфат ягыннан күп кенә уңай үзгәрешләр кичерде. Беренчедән, бу илдәге вазгыятьнең үзгәрүе белән бәйле булса, икенчедән, Уфада татар телендә вакытлы матбугат барлыкка килү, 1994 елдан Зәйнәп Биишева исемендәге Башкортстан «Китап» нәшриятында татар телендә дә китаплар бастыру мөмкинлеге тудырылу белән дә аңлатыла [Морзакаева]. Соңгы егерме елда әдәби-мәдәни мохитне җанландыру, татар телендәге тезмә һәм чәчмә әсәрләрне даими бастыру юнәлешендә «Кызыл таң» газетасы, «Тулпар» журналы аеруча нәтиҗәле эшли [Кәшфи]. Матбагаларның төрле жанрдагы проза әсәрләренә бәйгеләр игълан итүе, ел лауреатларын билгеләве, иҗади шәхесләрне үстерергә ярдәм итеп, әдәби барышны активлаштыра.

Туксанынчы елларга кадәр Таһир Таһиров, Суфиян Поварисов, Азат Магазов, Рәшит Сабитов, Әхмәт Әһлиуллин, Расих Ханнанов кебек өлкән буын әдипләре үз әсәрләрен башкорт телендә бастырган булсалар, «...80-90 нчы елларда байтак яшь язучылар, баштан ук кайсы әдәбиятка хезмәт итәчәкләрен ачык билгеләп, иҗат мәйданына килделәр» [Сафуанов, б. 315] һәм татар телендә китап бастыру мөмкинлегеннән файдаландылар. XX гасыр ахырында әдәбиятта үз каләмнәрен чарлаган тәҗрибәле буын (Закир Әкбәров, Эдуард Әгъзами, Рәшит Фазлыев, Альберт Котыев, Гали Гатауллин) белән бергә, яшь ягыннан шактый төрле булган бер төркем язучылар (Дилә Булгакова, Шәфига Исмәгыйлева, Кәрим Кара, Марат Кабиров, Дилбәр Булатова, Хисаметдин Исмәгыйлев, Айдар Зәкиев һ. б.), көчле дулкын булып, прозага килеп керде.

Билгеле булганча, Башкортстан җирлегендә татар телендәге әдәби процесс, гомумтатар сүз сәнгатенә хас булган кебек, билгеле бер традицияләргә нигезләнә, аны баету һәм үстерүдә эзләнүләрдән, буыннар алмашынуыннан тыш, идея-эстетик фикернең яңаруын тәэмин иткән үзгәрешләрдән дә азат түгел. Әдәби барыш – һәрвакыт хәрәкәттәге катлаулы күренеш. «Әдәбиятның билгеле бер юнәлештә үсә, әдәби закончалыклар һәм хасиятләрнең, бер әсәрдән икенчесенә, бер иҗаттан икенче иҗатка, бер чордан икенче чорга күчеп, аны баета һәм үзгәртә баруын әдәби барыш диләр» [Заһидуллина, Татар әдәбияты.., б. 73]. Башкортстандагы хәзерге татар прозасында, төрле эзләнүләр чорында да асылын югалтмаган реалистик сурәт чагылышы белән бергә, чор әдәбиятының, стиль тенденцияләрен, халкыбызның әхлакый һәм эстетик кыйммәтләренә тугры калган хәлдә, сурәтлелекнең яңа мөмкинлекләреннән оста файдалануын да ачык күрәбез [Халиуллина, 2016, б. 157].

XXI гасырның беренче елларында тарихи-биографик, гомумән, милли роман жанры үсешендәге уңышларны төбәк әдәбиятының казанышы буларак аерым билгеләргә кирәк. Бу чорда трилогия жанрының активлашуы, вакыйгаларны сурәтләүдә киңколачлылыкка, тарихилыкка омтылу хас. С. Поварисов, А. Магазов, Т. Таһиров кебек олпат язучылар, каләмнәренең осталык һәм фикер куәсе җитлегеп, укучыга әйтер сүзләрен күләмле жанр формасына салып тәкъдим иттеләр.

Тарихи-биографик жанр өлкәсендә Суфиян Поварисовның эшчәнлеге аеруча югары бәягә лаек. Бөек Ватан сугышы темасына багышланган «Язмыш корбаннары», «Канлы бәхет», «Ут эчендәге мәхәббәт» романнарын берләштергән тәүге трилогиясе язучының «Сайланма әсәрләр»ендә (2008) башкорт телендә басыла. Татар әдәбияты классигы, дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе Г.Ибраһимовка багышланган икенче трилогиясе язучы иҗатының гына түгел, гомумтатар сүз сәнгатенең уңышы буларак карала [Халиуллина, Региональные особенности..., 2016, б. 16]. Казанда һәм Уфада төрле елларда басылып чыккан өч роман («Пәйгамбәр таңы», «Күкнең җиденче катында», «Оҗмахка бер адым») язучы тормышындагы аерым чорны тасвирлауга, аның шәхес буларак формалашу юлларын, хис-кичерешләрен гәүдәләндерүгә багышланган. Әсәрдә кешеләр арасындагы шәхси бәйләнешләр һәм киң панорамалы тарихи вазгыять күренешләре уңышлы берләштерелгән, ягъни язучы, шәхес трагедиясен ачу белән бергә, гарасатлы чор картинасын сурәтләүгә дә ирешә. Катлаулы вакыйгалар, иҗтимагый, хисси-психологик һәм фәлсәфи катламнар белән чиратлашып, берберсен алыштырып килә. Аларның синтезында автор һәм герой чикләре җуела, фикри концепция уртаклыгы күзәтелә. Трилогиянең беренче кисәгендә Г. Ибраһимовның балалык, үсмер еллары, шәхес булып формалашу алшартлары күрсәтелсә, икенчесендә язучы һәм галимнең киңкырлы эшчәнлеге яктыртыла.

Өченче китап Г. Ибраһимовның шәхес культы елларындагы трагик язмышын, үзе инанып яшәгән идеология белән көрәш-алышын бәян итә. Романда геройның эчке кичерешләренә, фәлсәфи уйлануларына күп урын бирелү, үз җәлладлары белән очрашу, сорау алу моментларының аерым күренешләрдә генә күрсәтелү сәбәбен С. Сафуанов, С. Поварисов Уфада яшәгәнгә күрә, язучының «Г. Ибраһимовның тоткынлыкта үткәргән көннәрен, аңардан сорау алу материалларын тиешенчә өйрәнү мөмкинлеге булмавы» [Сафуанов, б. 317] белән бәйләп аңлата. Аның чәчмә әсәрләрендә көнчыгыш поэзиясе традицияләренә барып тоташкан югары стильгә хас тасвирлау алымнары оста кулланыла.

Азат Магазовның «Әйләнә тегермән ташы», «Ага сулар», «И бу дөнья…» романнарын үз эченә алган трилогиядә дә вакыйгалар киң эпик планда сурәтләнә. А. Магазовның «Әйләнә тегермән ташы» (1996) романы – үзгәртеп кору елларыннан соң Башкортстан «Китап» нәшриятында татар телендә басылган күләмле чәчмә әсәрләрнең беренчесе. Язучы үткән гасырның 20–30 елларында Башкортстан җирлегендә, Дим, Өязе буе авылларында булып үткән тарихи вакыйгаларны сурәтләгәндә, реаль шәхесләрне прототип итеп ала. Романда төрле катлам кешеләренең үзара мөнәсәбәте, халыкның көнитеше, фикер үсеше иҗтимагый борылышлар, фаҗигале вакыйгалар фонында тасвирлана. «Романның сюжеты, бигрәк тә вакыйгалар әнә шул иҗтимагый-социаль яссылыкта яктыртылганда, күптармакланып, отыры киңәеп китә» [Сафуанов, б. 331].

Билгеле булганча, А. Магазов прозага шигърияттә үзен сынап караганнан соң килә. Хәрби хезмәт тәҗрибәсенә нигезләнеп иҗат ителеп, очучылар тормышы, аларның батырлыгы яктыртылган «Шоңкар юлы», «Очу», «Атылган йолдызлар», «Тәүбә» повестьларын төрле елларда рус, башкорт телләрендә бастырып чыгара. Күпчелек әсәрләрендә язучы бөркетләрдән дә биегрәк күкләргә күтәрелгән кешеләр язмышын бәян итә, шулай ук «Кыраудан соң миләш тәмләнә» кебек повестенда әхлакый проблемаларны да күтәрә, яшәеш фәлсәфәсенә мөрәҗәгать итә. Очучылар темасыннан аерылгач, язучы ике катламда – җир һәм күк яссылыгында – сурәтләнгән вакыйгаларны фаҗига, ышаныч, иман төшенчәләре белән үзара үреп бирә, аның геройларында рухи ныклык, камиллеккә омтылыш ачык төсмерләнә.

Мәгълүм булганча, актив тормыш позициясендә торучы, бай тормыш тәҗрибәсенә ия иҗатчылар эссе жанрының бар мөмкинлекләрен иркен файдалана. Таһир Таһировның «Әрвахлар күктә яши», Камил Дәүләтшинның «Китек бәхет», Сәгыйдулла Хафизовның «Гомер фасыллары», Касыйм Йосыповның «Сикәлтәле гыйлем юллары» һ. б. язучыларның әсәрләрендә бу жанрга хас булган көчле лирик-эмоциональ башлангыч күзәтелә, иҗтимагый күренеш һәм вакыйгаларга карата тәнкыйди бәя шәхеснең субъектив фикер-кичерешләре белән үрелеп бара [Хәлиуллина, Сөләйманова, 2013, б. 7].

Т. Таһировның автобиографик фактларга нигезләнеп, эссе характерында язылган «Әрвахлар күктә яши» романы XX гасырның 30-90 еллар рухи атмосферасын тасвирлаган елъязма буларак кабул ителә [Сафуанов, б. 317]. «Эссе – ирекле композициягә корылган, нинди дә булса вакыйгаларны тасвирлаудан бигрәк, аңа карата авторның шәхси кичерешләрен һәм мөнәсәбәтен, уй-фикерләрен белдерә торган» [Әдәбият белеме..., б. 228] проза әсәре. «Әрвахлар күктә яши» әсәрендә композицион бөтенлектән читләшкән вакыйгалар чылбырында шәхес һәм җәмгыять мөнәсәбәте проблемасы күтәрелә. Романда шәхси-психологик кичерешләрнең һәм тормыш кануннарының сәяси-иҗтимагый карашлар белән каршылыгы тагын да кискенләшә төшә, «әсәр авторның үз биографиясе булудан бигрәк, сугыш алды елларыннан башлап 90 нчы еллар башына кадәрге вакыт эчендәге республика, ил биографиясе буларак кабул ителә; күп кенә җәмәгать эшлеклеләренең, әдәбият һәм сәнгать әһелләренең образлары җанландырыла» [Сафуанов, б. 318].

Әсәрдә язучының хатирә-күзаллаулар белән тергезелгән гомер мизгелләре, Зигана образында конкретлашып, фикерләр һәм геройлар полифониясенә нигез ролен үти. Зигана – тылсымлы, мавыктыргыч дөнья, матур хыяллар, изге гамәлләр иле. Егет белән бергә ул да үсә, үзгәрә, катлаулана, ләкин югалмый, идеаль, утопик өлге-үрнәк булып, гомер буена геройның күңелендә яши. Гомумән, бу образ асылына салынган фәлсәфә иҗтимагый тирәлеккә, җәмгыятькә бәя буларак кабул ителә башлый. Әсәрнең фактик-фактологик материалларга нигезләнүе сәнгатьлелек кануннарына зыян китерми, документаль-публицистик пафос хыялый-уйдырма катлам белән синкретик ярашып, күренекле шәхесләрнең җанлы

образларын тудырырга мөмкинлек бирә [Хәлиуллина, Сөләйманова, 2013, б. 31].

Әдәби барышның яңаруы, буыннар арасындагы бәйләнешнең тыгыз булуы ирешелгән уңышларны саклау һәм аларны иҗади үстерүдә дә ачык чагыла. Соңгы өч-дүрт ел эчендә туксан яшьләрен тутырып бакыйлыкка күчкән С. Поварисов, А. Магазов, Т. Таһиров, фәнни-педагогик хезмәткә бар көчен салып, язучы буларак «ачылып бетә» алмаган С. Сафуанов, К. Дәүләтшиннарның хәзер арабызда булмавы үзен сиздерә. Чорның бар каршылыкларын үз эченә сыйдырган романнар, сәнгать кануннарының бар нечкәлекләрен тоеп язылган, милләтебезнең гасырларга сузылган тарихын чагылдырган күләмле әсәрләр әлегә күренми. Аның каравы, Башкортстандагы хәзерге татар прозасында урта һәм кече күләмле проза әсәрләре күпләп языла, повесть алга киткән жанрларның берсе булып тора.

«Тарихи вакыйгаларны һәм иҗтимагый тормыш күренешләрен документаль материалларны анализлау юлы белән өйрәнгән документаль әдәбият» [Әдәбият белеме..., б. 49] өлкәсендә проза шактый уңышларга иреште. Бу уңайдан аталы-уллы Хәйдәр һәм Айдар Басыйровларның җәлилчеләр турындагы «Ватанга тугры калдылар», Тимергали Килмәтовның «Агач тәре юллап», Хәмит Сәлимовның «Порт-Артур юлы» китаплары, Вил Казыйханов, Рәфкать Рысаевның документаль повестьлары әдәби уйдырма һәм реаль фактларны, публицистик башлангычны оста куллана белү кебек сыйфатлары белән игътибарга лаек. Шуңа да басым ясап китү урынлы булыр: соңгы елларда сүз сәнгатенә хас булган синкретизм сыйфаты, әдәби синтез Башкортстандагы татар прозасын да читләтеп үтмәде. «Бер үк иҗат, хәтта аерым әсәр чикләрендә тарихи факт, фәлсәфи уйланулар, публицистик пафос, тәнкыйди башлангыч һәм әдәби кануннар очраша» [Хәлиуллина, Сөләйманова, 2013, б. 8].

Әдәбиятка журналистика аша килүчеләрнең күпчелегенә хас булганча, Эдуард Әгъзами әсәрләрендә реалистик, урыны белән документаль тормыш картиналары чагылыш таба, публицистик катлам ачык тоемлана. Тормыш һәм заман кануннарын яхшы белгән, мул тормыш тәҗрибәсенә, актив тормыш позициясенә ия язучы, көнүзәк һәм четерекле темаларга алынып, җәмгыять алдында торган җитди иҗтимагый һәм әхлакый проблемаларны күтәреп чыга. Әдип геройлары, гадәттә, ике төркемгә аерылып, намуслылык һәм хәйләкәрлек, гаделлек һәм золым, тыйнаклык һәм әрсезлек, киң күңеллелек һәм комсызлык кебек капма-каршы сыйфатларны гәүдәләндерәләр. Повестьларның уңай геройлары, төрле һөнәр ияләре булсалар да, аларны дөньяда үз хакыйкатен, хаклыкны, гаделлекне эзләү, ялкынланып, кимчелекләргә каршы чыгу сыйфаты берләштерә. «Хәбәрче суд юлында йөри», «Хаклык хакына», «Дөнья – куласа», «Сынау» һәм башка документаль әсәрләрдә шәхси көндәлеккә теркәлгән материаллар кулланыла, автор һәм аның замандашлары төп геройлар буларак хәрәкәт итә. Язучы әсәрләрендә автор позициясе ачык билгеләнеп, ул, тискәре күренешләрне катгый кире каккан хәлдә, үзе инанган идеалларны тайпылусыз, компромисска бирелмичә, ялкынланып яклый.

Расих Ханнанов прозасы ялкынлы журналист каләме белән язылган, көнүзәк мәсьәләләрне, кеше хәтерендә уелып калырдай вакыйгаларны сурәтләгән әсәрләрдән тора. Төрле жанрларда үзен сынап карау, журналистика һәм әдәбият каннунарын яхшы үзләштерү аның иҗатын күпкырлы итә. Соңгы елларда нәшер ителеп, шәхеснең рухи эзләнүләрен үз эченә алган публицистик язмалары да сәнгати сыйфатларга ия. Аерым очракларда проблемаларга хикәяләүченең субъектив фикере аша якын килү укучының үзенә дә әлеге вакыйгаларның шаһиты итеп тою иллюзиясен тудыра. «Тәмуг казанында» романында да, башка әсәрләрдәге кебек, авторның вакыйгалардагы каршылыкны тотып ала белүе, персонажлар сөйләмендә аларның үз урынын уңышлы билгеләве әдипнең үзен драматург буларак та сынап карауга китерә. Әсәр иҗтимагый вакыйгалар катламы белән фәлсәфи катламның органик синтезын тәшкил итә. Р. Ханнановның «Ишәк – җитәкче» (2006) исемле мәсәлләр, дини темага публицистик язмалардан торган «Кемгә ышанырга?» (2011) китаплары дөнья күрде. Башкортстанның халык шагыйре Әнгам Атнабаевның исемен мәңгеләштерүдә зур эш башкарып, «Бу җирне мин матурларга тудым» [Әнгам Атнабай] дигән күләмле истәлекләр җыентыгын төзеде. З. Биишеваның романнарын татарчага тәрҗемә итте.

Очерк остасы Мансаф Гыйләҗевның документаль-публицистик юнәлешне, тарихи прозаны үз итүе – табигый күренеш. Язучы әсәрләренең реаль вакыйгаларга нигезләнгән булуы публицистик башлангычны көчәйтсә, фәлсәфи-лирик катлам сәнгатьчәлек рухын

өсти. Әдәби уйдырманың аз булуы язучы каләменең сәнгатьлелеген, фикер мөмкинлеген чикләми, киресенчә, тәнкыйди фикернең тирәнлегенә, бәянең киңлегенә китерә. Сюжеттагы рациональ башлангыч бер әсәр чикләрендә статистик нәтиҗә, фактографик катлам һәм гыйбрәт синтезын хасил итә. М. Гыйләҗевның әдәби геройлары, кагыйдә буларак, кыю тормыш позициясенә, югары омтылышка ия затлар, гаделсез шартлар белән көрәш юлына басарга да мөмкиннәр, үз максатларына омтылып яшиләр. Барлык әсәрләрендә дә язучы җәмгыятьтә тамыр җәйгән иҗтимагый җитешсезлекләрне кискен фаш итә, шәхес һәм җәмгыять бәрелешен күрсәтә. Шәхеснең тарихи вакыйгалар фонында тоткан урынын күрсәтергә омтылу чорның һәм иҗтимагый корылышның кеше рухына тәэсирен ачыкларга ярдәм итә, үзбилгеләнеш мәсьәләсен калкытып куя.

М. Гыйләҗевның «Бәхет күктән төшми» (2015) повесте – вакыйгаларның төзеклеге, геройларның җанлылыгы, теленең сыгылмалылыгы һәм, иң мөһиме, композицион бөтенлеге белән уңыш казанырлык әсәр. Советлар Союзының соңгы еннәрен сурәтләгән картинада «Алга» колхозы мисалында XX гасыр ахырында – XXI гасыр башында таралып һәм таланып беткән күп хуҗалыклар язмышы күрсәтелә. Язучы «вакыйгаларны оста итеп үреп алып бара, әсәрнең сюжет эзлеклелеген, композицион бөтенлеген тәэмин итәрлек чараларны оста куллана» [Халиуллина, Региональные особенности..., б. 21]. М. Гыйләҗев совет системасының эчке корылышын тасвирлый, идеологик контекстлар белән уйнамый гына, үз карашын белдерә. Гомумиләштерүләр нигезендә ясалган нәтиҗә, милли асыл, шәхес иреге, кеше рухы кебек кыйммәтләрнең төрлечә бәяләнүе иҗтимагый шартларга бәйле булуын ассызыклап, укучыны хакыйкатькә алып килә. Әсәрләргә төзек тел хас, фикер сөреше логик эзлеклелеккә буйсына.

Рәшит Сабит прозасы традицион реалистик планда язылуы белән аерылып тора. Заманы өчен актуаль булган темаларны яктыртып, нигездә, әхлакый-иҗтимагый проблематиканы үзәккә ала. Язучының эстетик позициясе, аерым чор чикләрендә генә калмыйча, тормышның төрле этапларында сибелеп бирелә. Сюжет төзү остасы Р. Сабит чынбарлыктагы вакыйгаларның хронолик агышына (фабулага) караганда, аларны чуалтып, кирәк чакта гына укучы хөкеменә тапшырырга омтыла. Әсәр үзәгендәге вакыйга укучының игътибарын ахырга кадәр киеренкелектә тота ала. Табигать күренешләренең реалистик сурәте дә әсәрнең идея-эстетик куәсен арттыруга юнәлдерелә. «Өзелмәгән өметләр» повестенда сугыш чоры авырлыклары бер гаилә мисалында күрсәтелә. Гади халык җилкәсенә төшкән авырлыклар сәнгать чаралары ярдәмендә гомумиләштереп сурәтләнә. Сугыш фаҗигасен үткәргән буынның батырлыгына һәм фидакарьлегенә мәдхия буларак кабул ителә. Әсәрдә уңай герой концепциясе уңышлы чагылыш таба. Язучының «Мәхәббәт өянәге», «Ал офыклар», «Әрәмәдә ялбыр усак» һ.б. повестьларының төп геройлары – яшьләр, алар тормышта үз урынын эзләп, ялгышулар, күңел өзгәләнүләре аша чынбарлыкны кабул итәргә өйрәнәләр, самими һәм ихлас теләк омтылышлары белән табигать балалары буларак кабул ителәләр.

Әдәби эшләнеш һәм идея эчтәлеге ягыннан Гали Гатауллин хикәяләре аерым урында тора. Язучы драматик вакыйгаларны үзәккә алып, тормышның фаталь көчкә ия, урап үтәргә мөмкин булмаган хәлиткеч баскычында торган геройларның тирән һәм каршылыклы күңел кичерешләрен сурәтли. Сафлыкка, камилеккә омтылу яшәеш кануны буларак тәкъдим ителә, көндәлек ыгы-зыгыдан югарырак категорияләр барлыгы хакында искәртелә. «Язучы каләме тудырган һәр образ истә калырлык итеп, җете буяуларда сурәтләнә» [Хәлиуллина, 2009, б. 34]. «Карлыгачым, кара кашым», «Сагышлы бәхет», «Бер дога» әсәрләре – хикәя жанрының камил үрнәкләре. Әсәрләр лирик чигенешләргә, психологик халәтне ассызыклаучы табигать сурәтләренә бай. Ул, туган төбәге тарихын өйрәнүгә күп көч салып, «Без үзебез Таулардан», «Идәштәге илдәшләр», «Түреш белән күрешү», «Туганнарның табылган чагы» һ.б. китапларын нәшер итте.

Илдус Тимерханов исә эчке коллизияләргә, маҗаралы перипетияләргә, бер-бер артлы тезелеп килүче кискен борылышларга бай сюжет сызыгын үз итә. Индивидуалист герой үз бәхетен эзләү юлында көтелмәгән хәл-вакыйгаларга юлыга. Язучының әкият жанрында нәтиҗәле эшчәнлеге аның прозасына уңай йогынты ясый. Хикәяләү күп очракта төп герой исеменнән, хисси-психологик яссылыкта алып барыла, субъектив катлам белән беррәттән, чор картинасы да тергезелеп, иҗтимагый тирәлек бәян ителә. Язучы табигать күренешләрен сурәтләгәндә, гармоник колоритны тудыру, аллегорик паралельләр үткәрү, аларны

интерпретацияләүдә күптавышлылыкны булдыру осталыгына ия. Натурфилософик фәлсәфә шәрык әдәбиятыннан ук традиция булып килгән лирик агымга юл ача. Хатын-кыз гүзәллеге, саф мәхәббәт хисләре эстетик категория буларак гомумиләшә, мәхәббәт мизгелләре идеаль картина буларак күрсәтелә һәм, болар барысы да персонажларның романтик яссылыкта хәрәкәт итүенә китерә.

Шәфига Исмәгыйлева, Халисә Мөдәрисова, Дилә Булгакова, Зәйфә Салихова һ.б. хатын-кыз язучылар иҗатынннан үзгә бер җылылык, яктылык сирпелеп тора. Алар повесть-хикәяләрендә халкыбызның әхлакый-эстетик идеалларын ялкынланып яклыйлар, милли традицияләргә тугры калып, катлаулы язмышлы, бай хис-тойгылы геройларны гәүдәләндерәләр, шәхес һәм тирәлек бәрелешен әхлакый-психологик яссылыкта ачалар [Хәлиуллина, Сөләйманова, 2013, б. 9].

Шәхеснең җәмгыятьтә тоткан урыны, иҗтимагый корылышның кискен үзгәреше, гаилә институты, яшьләр тәрбиясе кебек темалар Ш. Исмәгыйлева иҗатында кызыл җеп булып сузыла. Аның күпчелек әсәрләрендә җәмгыятьтәге үзгәрешләргә әхлак кануннарыннан чыгып бәя бирелә. Вакыйгаларны композицион яктан оештыруда язучы эпиграф, тезмә текстлар, нәсер һәм эпистоляр жанр үрнәкләрен, милли бизәкләрне яратып куллана. Кайбер әсәрләрдә автор-скриптор образын күрергә мөмкин. Җырлар аша динамика, музыкаль ритм тоемлана, вакыт факторы калкытыла һәм интонацион сыгылмалык, художество категориясе булып кына калмый, ә әсәрне идея-мәгънәви югарылыкка да күтәрә. Гомумән, Ш. Исмәгыйлева телнең лексик, фразеологик, синтаксик мөмкинлекләреннән иркен файдалана.

Татар әдәбиятында шагыйрә буларак танылган Халисә Мөдәрисова соңгы елларда проза һәм драматургия өлкәсендә дә уңышка иреште. Язучы әсәрләрендә әхлакый-этик мәсьәләләрне үзәккә ала, кешеләр арасындагы нечкә мөнәсәбәтләрне яктырта, гадәти тормыш агышының көтелмәгән борылышларын күрсәтә, заманның тетрәндергеч проблемаларын күтәреп чыга. Геройның катлаулы иҗтимагый тирәлектә үз-үзен расларга омтылуы гомумкешелек кыйммәтләре хакында уйлануларга этәрә. Әсәрдән әсәргә күчә килгән фәлсәфи гомумиләштерүләр фикер офыкларын, яңача шәрехләү мөмкинлеген тагын да киңәйтә. Язучы фикеренчә, тормыш-яшәеш бәйгене хәтерләтә, һәр ярышта да җиңүче һәм җиңелүче булган кебек, фанилыкта һәркем үз урынын ала. Идея-эстетик мәгънә еш кына әсәрнең исемендә үк («Бәйге хакы», «Яр», «Соңгы сер») чагылыш таба. Яшь әдәбиятчы Р. Сөләйманов Х. Мөдәрисованың «Яр», Ш. Исмәгыйлеваның «Йөзекләр югалгач», Ф. Латыйпованың «Югалган бриллиант» повестьларын кырыс реализм үрнәкләре дип атады һәм «әдәбиятның чынбарлык хакыйкатенә йөз белән борылуы беркайчанда аңа хилафлык китермәде» [Сөләйманов, 2011, б. 240] дигән караштa тора.

Х. Мөдәрисованың «Соңгы сер» повесте әдәби материалы, темасы белән башка әсәрләрдән берникадәр аерыла. Төп сюжет сызыгы Бөек Ватан сугышы елларында әсирлектә булып кайткан герой күңелендә сакланган сергә бәйле вакыйгалар тирәсендә оеша. Тарихи-фактик мәгълүмат, иҗтимагый-тарихи детерминация совет чорын һәм аннан соңгы еллар үзгәрешләрен уңышлы күрсәтүгә мөмкинлек бирә. Хата-ялгышлар өчен җавап тоту, балалар-оныклар алдындагы бурыч мотивлары шәхси трагедия чикләреннән арынырга, язмыш һәм буыннар арасындагы бәйләнеш кебек мәңгелек сорауларга алып чыга. С. Хафизовның тематикасы белән Х. Мөдәрисова әсәренә якын торган «Алман күчтәнәче» повестенда да охшаш фәлсәфи уйланулар зур урын ала.

Дилә Булгакованың шигъриятендә һәм чәчмә әсәрләрендә геройның тирән күңел кичерешләре, ашкынулы хис-тойгылары жанрара бәйләнешләр яссылыгында ачыла. Язучы нәфис шигъри сурәт һәм тормыш тәҗрибәсе синтезына оста ирешә. Бу хасиятләр язучыга нәсер жанрында уңышлы иҗат итәргә мөмкинлек бирә. Автор милли эстетикага тугрылыклы, традицион образларга, табигать күренешләрен җанландыруга игътибарлы. Соңгы чор әсәрләренә дини мотивлар килеп керү язучы иҗатының тематикасын киңәйтә. Билгеле булганча, Д. Булгакова алты ел төрмәнең хирургия бүлегендә шәфкать туташы булып эшли. Шәхси тормыш тәҗрибәсе нигезендә тоткынлык темасына язылган әсәрләре психологик тирәнлек һәм характерларның индивидуальлеге белән аерылып торалар. Аларда чынбарлык һәм шәхес каршылыгының төп сәбәпләрен ачыклау омтылышы прозаикка геройларның уй-кичерешләрен, эш-гамәлләрен тирән психологик аспектта ачуга мөмкинлек бирә. Мәсәлән, «Бабай җаны», «Болан күзе», «Гафу ит мине,

картинәм!», «Шомырт күз», «Төнге кунак», «Ай-дага», «Елама, сеңлем!» хикәяләрендә тормыш, куркыныч, җинаятьчел вакыйгаларда гәүдәләнгән геройлар рухи газаплар, сызлану, гаҗизлек кебек экзистенциаль чикләрдә күрсәтелә. Автор әсәр идеясен, гомумкешелек кыйммәтләренең әһәмиятен көчәйтү максатыннан хронотопны оста файдалана. Вакыйгалар, билгеле булганча, ябык, чикләнгән пространствода – зиндан, төрмә диварларында сурәтләнә. Иреккә чыкканнар – мәгълүм сәбәпләр аркасында якыннарын югалткан, я булмаса туганнарыннан рухи ераклашкан геройлар, табигатькә якынаеп, аннан яшәүгә көч ала. Зиндандагы геройларның тормыштагы максаты – иреккә чыгу, якыннары белән очрашу, үзенең кешелек сыйфатларын исбатлау.

Хәзерге татар прозасында Марат Кәбировның иҗаты күләме һәм сыйфаты ягыннан аерылып тора. Иҗатының чишмә башы Башкортстанда булган әдип, туган җирендә язучы буларак «өлгереп җитеп», башка күп кенә якташ язучыларның язмышын кабатлап, Казанга күченеп китте. Бу тенденция, аның иҗтимагый-сәяси, мәдәни сәбәпләре, аңа гыйльми-тәнкыйди фикернең мөнәсәбәте Башкортстандагы татар поэзиясе мисалында И. Фазлетдинов тарафыннан җентекле шәрехләнә [Фазлетдинов, б. 64–65]. Әдәбиятка шагыйрь буларак килеп кергән М. Кәбировның беренче күләмле чәчмә әсәрләрендә үк яңача фикерләү, үзгә стиль тенденцияләре тоемлана, аның прозасы берничә иҗат юнәлешенең синтезы белән кызыклы. Язучыга әдәби экспериментлар ят түгел. Бер әсәр чикләрендә реалистик һәм романтик сурәтне дә, шартлы-метафорик катламны да, мул натуралистик буяуларны да, постмодернистик тенденцияләрне дә күзәтергә мөмкин. Нәтиҗәдә дөнья әдәбиятында үсеш алган яңа алымнар милли җирлектә тергезелеп, татар укучысына интеллектуаль проза үрнәкләре тәкъдим ителсә дә, язучының эстетик инанулары әдәбиятыбызның традицион рухында: аның геройлары (Акбабай, Мәдинә, Гөлзилә һ. б.) иман, сабырлык кебек әхлак кыйммәтләренә тугрылыклы кала.

М. Кәбировның «Мәхәббәт яңгыры», «Мәхәббәттән җырлар кала» һ. б. повестьлары, исеменнән үк күренгәнчә, кешеләрнең бер-берсенә булган иң нечкә хисләренә дан җырласа, «Сары йортлар сере», «Акбайның туган көне» әсәрләре иҗтимагый-фәлсәфи катламы белән кыйммәтле. «Китап», «Дүртенче үлчәм», «Канатлы кеше» әсәрләре постмодернистик әдәбият үрнәкләре буларак үзенчәлекле. Сәнгатьчә сурәтләү чараларының оригинальлеге белән «Сары йортлар сере» повесте әдәби җәмәгатьчелекнең игътибарын җәлеп итте. Ф. Латыйфи повестьны «татар әдәбиятының гына түгел, гомумән, хәзерге заман әдәбиятының иң мөкәммәл һәм тирән эчтәлекле» [Латыйфи, б. 138] әсәре дип бәяләде. Каләмдәше хакында фикерен дәвам итеп, болай диде: «Никадәр тыгызлык, экспрессия, читләтеп әйтә белү... Повестька тормыш чынбарлыгының бөтен кабәхәтлеге, «изге максатлар» хакына, ди-ди, халыкларга карата үткәрелгән телсезлек, динсезлек, йоласызлык, милләтсезлек сәясәтенең бөтен ачылыгы, аның кешеләрдән эш малы, эш хайваны ясавы бөтен тирәнлеге белән, осталарча чагылдырылган» [Латыйфи, б. 138]. Д. Заһидуллина тарафыннан повестьның идея-эчтәлек катламына тәфсилле анализ бирелә: «Әсәрнең вакыйгалар катламы да, төзелеше дә, фәлсәфи катлам да бер фикергә алып килә: кешеләр ерткыч, кол, мескен хәлендә яшиләр. Аларны рухи «доктор» да, изге Ана да, гөнаһсыз сабый да үзгәртә, үз халәтләренә күзләрен ача алмый» [Заһидуллина, Яңа дулкында, 2006, б. 170]. Илдә дистә еллар буена яшәп килгән тәртипләр, югары катламның гади кешеләр язмышына битарафлыгы тирән фәлсәфи уйлануларга этәрә. Гыйльми-тәнкыйди фикер әсәрнең үзенчәлекле сурәтләү алымнарын да билгеләде: «Биредә пастиш, ирония, чиктән тыш арттырылып, абсурд чигенә җиткерелгән һәм социалистик тормышны гротеск формасында, антиутопия итеп сурәтләү урын тапкан» [Заһидуллина, 2004, б. 139]. Әсәр, Башкортстан матбугатында басылып чыгу белән, С. Сафуанов [Сафуанов, б. 322–323], Л. Сәгыйдуллина [Сәгыйдуллина, б. 48–50], Р. Фәтхерахманов [Фәтхерахманов, б. 142–149] һ. б. тарафыннан да уңай фикер әйтелде. «Сары йортлар сере» повестендагы үзәк герой гәүдәләнеше А. Хәлиуллина [Хәлиуллина, 2007] тарафыннан Ф. Бәйрәмованың «Соңгы намаз» әсәре белән чагыштырма яссылыкта тикшерелде. Шулай ук М. Кәбиров повестьларында афористик фикер бирелеше [Хәлиуллина, М. Кәбиров повестьларында, 2011, б. 154-156] аерым каралды. Хәзерге татар әдәбиятында язучы прозасы постмодернистик күренеш буларак Л. Йөзмөхәммәтова [Юзмухаметова, б. 18] тарафыннан җентекле анализланды. Соңгы елларда язылган берничә кандидатлык диссертациясендә әдип прозасының

тикшеренү предметы булуы, язучының әдәби барышка алып килгән яңалыгы хакында сөйли.

Язучы буларак Башкортстанда танылу алып, иҗади эшчәнлеген Татарстанда дәвам итүчеләрнең тагын берсе – Кәрим Кара (Һади Кәримов). С. Сафуанов «Башкортстанда повесть жанры өстендә аеруча уңышлы эшләүче өч язучы» [Сафуанов, б. 321] арасыннан беренче итеп аның исемен атый. Язучының повестьлары һәм хикәяләре тупланган «Без әнкәй йөрәгеннән чыктык» җыентыгы 2009 елда Уфада, «Ак күгәрчен, күк күгәрчен» китабы 2014 елда Казанда басылып чыкты.

К. Кара әсәрләре XX гасыр ахыры – XXI гасыр башында илдә барган үзгәрешләрне, чынбарлыкның катлаулы күренешләрен сәнгатьчә чагылдыра. «Иҗтимагый атмосфераны төрле детальләрдә тулы бер картина итеп сурәтләп, заманга хас проблемаларны кабатланмас типлар, образлар язмышы аша ачып сала» [Хәлиуллина, б. 261]. Геройларның, яңа мөмкинлекләргә кызыгып, еш кына туры юлдан тайпылулары, тормышның бер этабында тукталып калып, рухи кыйбла эзләүләре, кайберләренең, иҗтимагый үзгәрешләрне акыл белән кабул итә алмыйча, дөнья шавына артык биреүләре үзгәртеп кору хәрәкәте тудырган иҗтимагый-психологик вазгыять буларак кабул ителә. Иҗтимагый үзгәрешләрне кешеләр күңеленә аларның нинди йогынты ясавыннан чыгып бәяләү К. Кара иҗатын, «негатив» проза («кара проза») юнәлешеннән бигрәк, психологик яки иҗтимагый (социаль) реализм яктылыгында карарга мөмкинлек бирә.

К. Караның төрле елларда иҗат ителгән күпсанлы әсәрләре арасыннан «Гафу ит мине», «Шаяру», «Инфаркт», «Лашбайга сәяхәт», «Качкын», «Принцлар һәм принцессалар», «Банан Хисами», «Көнбагыш сатучы», «Без әнкәй йөрәгеннән чыктык» кебек повестьларында лирик-эмоциональ башлангычның да көчле булуын билгеләргә кирәк. Аның яңа форма эзләү тәҗрибәсе уңышлы: автор әдәби бизәкләр белән артык мавыкмый, әсәр тукымасын махсус катлауландырмый һәм киң катлам укучылар өчен җиңел аңлаешлы тел-стиль алымына мөрәҗәгать итә. Язучы әсәрләренең күбесендә «автор концепциясенең мәгънәви тирәнлеген ачарга юл күрсәтүче өлеш», сюжетны бер җепкә җыеп тотучы, аны хәрәкәтләндерүче уртак мотив – ялгышу мотивының бирелүе чорның тулы картинасын тудыруга, геройларны тулырак аңларга мөмкинлек бирә. Тик һәр геройның үз язмышы, һәр ситуациянең үз интригасы булган кебек, ялгышка илткән сукмак-юллар да, сәбәпләр дә төрле. Мәсәлән, «Шаяру»дагы Марат, байлык артыннан куып, «Принцлар һәм принцессалар»дагы Нурия, үз хыял дөньясында тудырган принцны көтеп, чын хакыйкатьне төшенә алмый ялган эчендә яшәве белән ялгыша, «Качкын»дагы Сәлим, тирә-яктагылар белән конфликтка кереп, сынауларга түзә алмыйча, ялгышлык эшли, «Лашбайга сәяхәт»тәге Фәрит үз-үзен алдап яшәве белән хакыйкатьтән читләшә. Ялганның ачылуы геройларга рухи сынау, күңел газаплары алып килсә дә, чынбарлык белән очрашу, хакыйкать аларны үткәннәргә бәя бирергә, тормыш-яшәеш асылы турында уйланырга мәҗбүр итә.

К. Кара повестьларының аерым берләренә ялгышу, алдану белән янәшә, шуның нәтиҗәсе буларак, ялгызлык мотивы да килеп керә. Өметсезлек чикләренә ташланган Фәрит тә («Лашбайга сәяхәт»), Марат та («Шаяру») яңача яшәргә тиешлеген төшенә; Нурия исә («Принцлар һәм принцессалар») чарасызлыктан үз хыялын җимерә, баласын ялгыз үстергән Ана («Без әнкәй йөрәгеннән чыктык») күпме рәнҗетү-сынауларга дучар була. Ялгызлыкны җиңүнең бердәндер юлы төсендә мәхәббәтне, гаиләле булуны тану гомумкешелек фәлсәфәсен конкрет җирлектә тергезә. Чынбарлыкның көтелмәгән ваклыклары алдында каушап-куркып калу, күнегелгән яшәү рәвешен үзгәртергә әзер булмау әсәрләрдә курку мотивы буларак калкып чыга. Курку җәмгыять һәм кеше арасындагы бәйләнешне өзү белән яный, билгесезлек алдында калган геройга рухи газаплар алып килә. Эчке куркуны җиңү өчен, һәр герой диярлек башка бер кабыкка төренеп яшәргә мәҗбүр ителә.

«Без әнкәй йөрәгеннән чыктык» повесте [Кәрим Кара], әдәбият белемендә монтажлау термины белән йөртелеп, сурәтләүнең өзек-өзек фрагментлардан торуын күз уңында тоткан композицион берәмлеккә корылган. Шуңа да әлеге әдәби әсәрне оештыруда сәбәп-нәтиҗә бәйләнеше (детерминация) түгел, ә авторның фикерен бәйләп торучы вакыйгалар тезмәсе төп рольне уйный. Сюжетны бер фокуста тотучы доминант кисәк булып Ана образы тора. Биш бүлек һәм соңгы сүз (пролог) ана хәтерендә тергезелгән вакыйгаларны һәм геройның аларга мөнәсәбәтен чагылдыра, я булмаса хәтердә калган мизгелләрне искә төшерү рәвешендә бирелә, вакыйгаларның дәвамы бәян ителә

Хикәяләүче тормышындагы тәэсирле күренешләр лирик башлангыч аша бирелә һәм чор картинасын да, шәхси фаҗигане дә үз эченә ала. Әсәр шуның белән үзенчәлекле: балалык самимилеге, күңел чисталыгы бөркелеп торган герой монологы фәлфәси уйланулар белән баетыла һәм бала күңелендәге үзгәреш-үсеш эволюциясен, тормышны танып белү процессын тоемларга ярдәм итә. Вакыйгаларның фабулага корылуы, хикәяләүченең дә төп сюжетка ияреп баруы әсәр композициясен текст композициясеннән ераклаштыра һәм аның ачык тибына тәңгәл килә. Һәрберсе, мөстәкыйльлеккә ия булып, яңа исем белән аталган бүлекләр ана һәм бала диалогын хәтерләтә, беренчесенең сөйләмендә, тормышның ачысын да төчесен дә татыган кеше буларак, объектив бәя-нәтиҗәләр бирелсә, икенчесенең хәтерендә субъективизм, вакыйгаларны хис-кичерешләр аша бәяләү өстенлек итә. Әдәби әсәргә генә түгел, тулы бер китапка исем буларак бирелгән «Без әнкәй йөрәгеннән чыктык» атамасы һәр яңа әсәр нигезендә полифоник яңгыраш ала. Китапка тупланган әсәрләр повестьтагы субъектив идея белән ассоциацияләшә төшәләр, нинди генә язмышка дучар булсак та, без газизләрдән-газиз әниләр тарафыннан дөньяга килгән, аның йөрәк тибешен тоеп аваз салган кешеләр, дип әйтергә тели автор.

К. Кара геройларының гендор аспектта гәүдәләнеше үзенчәлекле. Әсәрләрдә ир-ат һәм хатын-кыз җенесендәге геройлар, үзара үрелеп, һәрберсе үз характерлары белән сурәтләнә. Язучы өчен, әлбәттә, иң изге кеше – Ана. Аның белән бәйләнешле вакыйгалар тасвирланганда, язучы югары идеаллар һәм кешелек кануннары турында уйларга урын калдыра. Традицион образлар, архетиплар галереясын тулыландырып, Аналарга мәдхия укый. Мәңге айнымас иренең хатасы аркасында ике улын югалткан Нәзирә дә («Гафу ит мине...»), ялгызлыкның ачысын татыган Ана да («Без әнкәй йөрәгеннән чыктык»), әсәрләргә эпизодик характерда кертелгән башка аналар да – бөек затлар. Әмма аерым әсәрләрдә хатын-кызлар, бигрәк тә ир хатыннары гәүдәләнешендә берьяклылык күзгә ташлана. Бүләк һәм байлык кына көтеп ятучы Лиана («Шаяру»), үзен башкалардан өстен тотучы Диана («Инфаркт»), иренә генә түгел, баласына да кешелексез Сания («Лашбайга сәяхәт»), ярты көнен урамда хәбәр җыеп, ә калганын йоклап уздыручы Сәрвиназ («Банан Хисами») образларының әхлакый йөзен ачу максатыннан кулланылган кара буяулар – детальләр, ирләре телендәге аларга бәя булып яңгыраган «кыямәт ыржыгы», «ләгънәт» сүзләре югарыда әйтелгән фикерне раслый.

Соңгы елларда Башкортстанда татар телендә иҗат итүче язучылар арасында Хисаметдин Исмәгыйлев каләме аерылып тора. Стәрлебаш районында авылда яшәп, гомере буе ветеринар булып эшләгән, иҗатка шактый тормыш тәҗрибәсе туплагач кына килеп кергән прозаикның кайсы гына әсәрен алсаң да, ул бер сулыш белән үз дөньясына алып кереп китү көченә ия. Нинди генә жанрда язылуга карамастан, сюжетның мавыктыргыч, хикмәтле вакыйгаларга корылуы һәр әсәрне үзара берләштерүче сыйфат булып тора.

Очраклы вакыйгалар тәэсирендә геройлар язмышының көтмәгәндә кискен борылыш алуы автор әсәрләрендә маҗаралыкны тудыра. Мәсәлән, Җәүдәт Әфганстан, Үзбәкстан җирләрен гизә («Калымчы Җәүдәт»), Фәйзулланы язмыш Таҗикстанга илтеп ташлый, исеме сер булып калган башка бер герой Сахалинга, аннан Япония җиренә кадәр барып чыга («Сак-Сок»). Тыныч кына көн итеп яткан герой, һич югында, күрше авылга барып булса да, язмышын үзгәртә («Су анасы»). Төп сәбәп, җитди, әллә ни зур булмаса да, сәерлеге белән укучыны үзенә тарта. Язучының «Фәйзулла», «Калымчы Җәүдәт» повестьларының үзәгендә дә чит җирдә яшәгән, «Явурай» хикәясендә тормыш сынауларына дучар булган кешеләр язмышы күрсәтелә. Наркомания, эчкечелек кебек проблемалар да калкытылган әлеге әсәрләр матур мәхәббәт тарихлары белән үрелеп бара. Шуны да искәртергә кирәк: Х.Исмәгыйлев тергезгән мәхәббәт тарихлары да үзенчәлекле, сөю-сөешү картиналарын язучы җентекләп, хисчән шагыйранә итеп сурәтли («Су анасы»). Язучының «Зимагулар» повесте алтын приискасыннан качкан Басурман һәм Мансур язмышларын бәян итә. «Үлем тырнагыннан ычкынып, бар көчләренә ыреккә талпынган, адәм баласы түзә алмаслык авырлыкларны үз башыннан үткәргән качаклар язмышын, ышандыргыч һәм сурәтле итеп, бәйнә-бәйнә сөйләп бирә автор» [Кәшфи, б. 181].

Х.Исмәгыйлевның әдәби эшчәнлегенә шәркый традицияләр, халык авыз иҗаты үрнәкләренә мөрәҗәгать итү хас. Әсәрләрнең бер өлеше тартмалы композициягә («кысалы кыйсса») корылган булса, бер төркеме әкият, мәзәк, сөйләкне хәтерләтә. Кайбер очракта

хикәяләүче төп вакыйгадан бөтенләй читтә кала, бары күзәтүче буларак кына катнаша. «Яңа чор язучылар иҗатында шәркый традицияләрнең, халык авыз иҗаты үрнәкләренең (бәет, әкият, сөйләк, мәзәк) заманча чагылышы өлгесен күрсәтергә кирәк булса, бу сыйфатларны Хисаметдин Исмәгыйлев әсәрләрендә күпләп табарга мөмкин» [Хәлиуллина, 2013, б 189]. Әсәр үзәгендә бер төп герой, сюжетның кискен борылышлары (перипетияләр), көтелмәгән ситуацияләр, маҗаралы вакыйгалар, каймалы композиция – болар бар да халык авыз иҗатыннан килгән традицияләр.

Дилбәр Булатованың тәүге әдәби тәҗрибәләрендә үк язучының стиль үзенчәлекләре сиземләнә. Шәхси кичерешләр үзәккә чыгарылган «Бүген бездә коръән ашы» (1993) исемле беренче язмасында нәсер жанрының сыйфатлары күзәтелә. Чәчмә текст юллары арасында тоемланган эчке ритм, сүзләрнең үзара аваздаш (ритмик) яңгырашы композицион бөтенлеккә ирешергә мөмкинлек бирә. Әлеге жанр хасиятләре авторның башлангыч чорда язылган «Зәңгәр күлдә өч торна», «Күлмәк», соңрак иҗат ителгән «Кунак мунчасы»нда да күзәтелә. Иҗатчының табигать күренешләрен җанлы һәм кабатланмас итеп сурәтли белү осталыгы да – аның каләме үзенчәлекләреннән берсе. Г. Ибраһимов, Ш. Камал, М. Әмир һ. б. татар әдипләре традицияләре рухында язылган бу әсәрләрдә кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрне ачу белән янәшә табигатькә мәдхия укыла, кеше һәм табигать арасындагы берлек, гомумгармония күрсәтелә, «геройның каршылыклы һәм катлаулы күңел дөньясын символик, метафорик һәм сурәтләү чаралары ярдәмендә күрсәтүгә ирешелә» [Yusupov, Gilazov, б. 346].

Безнең карашка, тормыш-яшәешне көтелмәгән ягы белән ача белү хасияте Д. Булатова прозасын башкалардан аерып тора. «Хикәяләренең үзенчәлеге дә шунда: ул кеше тормышында беренче карашка әллә ни катлаулы булмаган вакыйга-күренешләрне тергезә, аларның герой күңелендә нинди нинди эз калдыруына игътибарын юнәлтә. Вакыйгалар экстремаль түгел, һәркем тормышында очрарга мөмкиннәр, әмма алар геройны тетрәндерү көченә ия» [Хәлиуллина, Чиләккә йолдыз җыеп, 2011, б. 36]. Күнегелгән тормыш агымыннан чит мохиткә, гадәти булмаган тирәлеккә эләккән герой үз-үзен тотышы, уй-хәрәкәтләре аша күңел төбендә йөрткән, үзе дә белмәгән сыйфатлары белән ачылып китә. «Лифт»та, мәсәлән, көндәлек ыгы-зыгысы тукталып, геройлар чарасыз «читлек»тә – лифтта бикләнеп калалар һәм, горурлыкларын җиңеп, бер-берсенә күңел-ләрен ачалар. Лифт күңел баскычларыннан югарыга, яңа этапка күтәрелү мөмкинлеген символлаштыручы образ булып тора.

Д. Булатованың «Күлмәк» хикәясе, авылга кыргый капитализм мөнәсәбәтләренең үтеп керә башлавын сурәтләү белән беррәттән, рухи проблематиканы да күтәрә. Рәшит сабантуйда, талпынып, әлегә беркем дә менә алмаган туры колгага үрләп, мәйдан өстенә караш ташлый. Гади генә, хәтта мескен генә күренгән, яңа елдан соң сабантуй уңаеннан гына күпмедер эш хакы ала алган авыл иренең күңел матурлыгы шушы эпизодта бар тулылыгында ачыла. Ләкин тән дигәнең җиргә мохтаҗ, җирнең үз законнары. Анда төшкәч, Рәшит гүя кечерәеп, югалып кала, бүләккә очсызлы гына бала сандалилары алып, түгәрәктән чыгып китәргә ашыга. Хәзер инде ул гадәти «күлмәген» кия – өйрәнелгән, гадәти тормышын дәвам итә. Бу герой да «үсү, балалыктан чыгу» этабын үтә, аның беркатлылык, тиз ышанучанлык сыйфатын сыйныфташы – үткен, елгыр Нәҗип бик тиз дәвалый. «Кое»дагы геройларның хәрәкәт векторы, киресенчә, аска, җиргә таба юнәлгән. Биредәге кое образы, эчәр су чыганагы гына түгел, ул хикмәт, тормыш тәҗрибәсе туплау фәлсәфи мәгънәсен дә үз эченә ала. Тереклек итәргә саф суны чыгару өчен, ком-таш катламнарын үтеп, бик тирәнгә төшәргә кирәк булган кебек, иман, мәрхә-мәтлелек, аек акыл сыман гүзәл сыйфатларның мәңгелек чыганагы һәркемнең күңелендә. Ә аңа һәркем үз юлы, омтылышы белән ирешә (Балбабай, малай), ә кемнеңдер, килеп җиттем дигәндә, сабырлыгы бетә (әти образы).

Д. Булатова хикәяләрендә төп герой нindider бер мизгелдә, башка рухи катламга күчә: ул гаҗәпләнә, газаплана, гарьләнә – көчле хисси тетрәнү кичерә һәм бу халәт аның тормышына, холкына тәэсир итә, хәтта вакытның гадәти агымын үзгәрткәндәй була. Әсәрнең кульминацион ноктасында аның җаны гүя, канат җилпеп, гадәти тормыш шартларыннан арынып, үткәнгә, хәзергегә, киләчәккә биектәнме, читтәнрәкме караш ташлап ала. Рәһинә («Онык»), Рәшит («Күлмәк»), Зөбәрҗәт («Зәңгәр күлдә өч торна»), Малай («Кое»), Фәрит белән Фәридә («Лифт»), Егет («Сакчы») – барысы да

четерекле тормыш ситуацияләрендә калып сабак алалар һәм автор тарафыннан әлеге ачы тәҗрибә аларны киләчәктә ялгышлардан саклар дигән фикер үткәрелә.

Язучының идеал геройлары – озын гомер юлы үтеп, акыл туплаган, тышкы һәм эчке гармониягә ирешкән, сабыр, гыйсъяный гамәлләрдән азат шәхесләр: Ана образы («Командировка»да – Мәрьям, «Кунак мунчасы»нда – картәни), Риза карт («Риза»). Алар, югарыда ассызыкланган геройлар системасыннан аермалы буларак, автор тәкъдим иткән четерекле ситуацияне рухи-фикри яктан әзерлек белән каршылыйлар, (әрсез журналист белән очрашу («Командировка», «Риза»), йортны югалту («Кунак мунчасы»). Әлеге үзенчәлек авторның ислам һәм шәригать кануннары нигезендә көнитеше белән дә аңлатыла. «Риза» әсәрендә, XX йөз башы татар хикәяләреннән килгән яшәү һәм үлем фәлсәфәсе яңа материалда чагылыш табып, «җир тормышының кадере хакындагы идея үткәрелә» [Гилазов, б. 207].

Д. Булатова, хикәяләренең идея эчтәлеген көчәйтү максаты белән, төрле детальләрдән отышлы файдалана. Мәсәлән, ут «Ачык ишекләр көне»ндәге Зөбәерне битарафлык, төшенкелек халәтенә төшерсә, «Кунак мунчасы»нда ул карчыкның тәкъдиренә язылган сынау буларак кабул ителә. Төрле вариацияләрдә чагылыш тапкан су образына, күпчелек очракта, чистарыну, котылуга, хикмәткә ирешү мәгънәсе йөкләнә. «Зәңгәр күлдә өч торна» һәм «Кое»да, хикәяләрнең исеменнән үк аңлашылуынча, күл һәм кое, «Кунак мунчасы»нда – кар көртләре, «Туй»да – чишмә һ.б. Карга, бозга, парга әверелгәндә дә, су үзенең үзенчәлеген югалтмаган кебек, күпчелек геройлар, нигездә, җан асылларына тугры калып, аларның киләчәкләре өметле булып күзаллана. Хикәяләрнең исемнәре, үз эченә төрле катламдагы мәгънә төсмерләре алып, әсәрнең «ачкычы» шунда яшерелгән бер сүз белән генә бирелә. Күренә ки, хикәяләрдә геройларның тышкы тирәлек белән тартышы түгел, эчке конфликт күбрәк урын били, психологизм алымына, эчке сөйләмгә мөрәҗәгать ителә, реалистик сурәтләү ысулы кулланыла. Хисләр гаммасы артык ярсу, шашкын түгел, төсләр кулланылышы да җете, катгый орнаменттан бигрәк, ярымтоннарга, табигый колоритка ия реалистик пейзажны хәтерләтә.

Моңа кадәр хикәя жанрында эшләгән Д.Булатованың «Җантөяк» (2010) дигән беренче повесте, безнең карашка, югарыда ассызыкланган барлык үзенчәлекләрне бер төенгә төйнәгән [Хәлиуллина, 2013: 236]. Авторның тәүге нәсерендә үк бөреләнгән рухи эзләнүләре, идея-эстетик идеаллары Галия һәм Таһир образларында сәнгатьчә чагылыш таба. «Борынгы ядкәрләребездәге төрки хатын-кыз асылына хилафлык итмәгән, Галимҗан Ибраһимовтагы татар хатыны кебек, классик үрнәкләрне куәтләгән Галия образы үзенең эчке оптимизмы, характерның умыртка баганасын хасил иткән түземлеге, сиземлелеге, рухи каһарманлыгы, яшәешкә мәхәббәте белән көчле» [Кәшфи, б. 292–293]. Язучының «Котәрмен, дигән идең...» (2017) повесте кешелеклелек кануннары, мәхәббәт һәм нәфрәт кебек төшенчәләр хакында уйланырга чакыра.

Айдар Зәкиев – бүгенге көндә Башкортстанда татарча иҗат иткән талантлы язучылар арасында иң яше булып, беренче тәҗрибәләреннән үк үзен яңа юнәлештә сынап караган, күләмле һәм нәтиҗәле эшләве белән аерылып торган каләм иясе. «Кешеләр илендә» җыентыгы басылып чыккач та, аның иҗатына киң җәмәгатьчелек һәм тәнкыйтьчеләр игътибар итте. Әдәбият галиме С. Хафизов: «А.Зәкиевнең «Кешеләр илендә» китабы аз да түгел, күп тә түгел, милли прозада заманны яңача сурәтләү юлында бер эксперимент ул» [Хафизов, б. 4], – дип язып чыкты. М. Кәбиров каләмдәшенең үзенчәлеген түбәндәгечә бәяли: «Айдар беркемне дә кабатларга теләми, үз сукмагын, үз стилен табарга тырыша. Татар әдәбиятында аны беркем белән дә чагыштырып булмый» [Кәбиров, б. 20].

Динамик үсештә бирелгән вакыйгаларның билгесезлек ноктасында төгәлләнүе геройны гына түгел, укучыны да үсү-үзгәрү, күзәтү-кичерү юлына алып чыга. Язучы каләменә геройларны психологик типлар буларак ачу омтылышы да хас. Җәмгыятькә, тирә-яктагыларга, шулай ук үз-үзләренә дә таләпчән, тормыш басымына каршы тора алырлык геройлар авыр сынаулар узарга дучар ителәләр һәм гармоник дөнья моделен эзләү, аңа омтылу теләгенә тугры калалар. «Тамчы да ялганламый, икейөзләнми, тормышны ничек бар, шулай тасвирларга тырыша. Мондый турылык, әлбәттә, еш кына әсәрләрен карасоры төсмерләрдә сурәтләүгә китерә» [Сөләйманов, 2014, б. 49]. Төрле вакыт катламнарын янәшә тергезү, кайбер очракларда мифологик материалны отышлы файдалану, сурәтләнгән вакыйгаларның сюжет тукымасы-

на катлы-катлы булып ятуы, урыны белән натуралистик детальләрнең дә күзәтелүе әсәрне төрлечә кабул итү мөмкинлегенә урын калдыра, димәк, интеллектуаль тенденцияле башлангыч үсеш ала.

Башкортстандагы татар әдәбиятының юмор-сатира юнәлеше дә әдәби көчләргә бай. Рәүф Хәкимов («Кемнең бүреге җылырак?», (2004), Рәшит Фазлый («Таракан харап итте», (2005), Риф Мөхәммәтов («Буйдаклар җыелышы», (1994), Зәниф Сәетов («Бизәкле кыршау», (1997), Инсур Мөсәнниф («Озак яшәү сере», (1999), Рәис Риян («Галәмәт» (2010) сатирик җыентыкларын бастырып чыгардылар. М.Салтыков-Щедрин, А.Чехов һ.б. язучыларның иҗат үзенчәлеге булган иҗтимагый сатира З. Әкбәров прозасында милли җирлектә чагылыш таба. Камил Фазлый, Габдулла Вафин үзләрен сатирик проза остасы буларак таныттылар. «Мәетләр тирләми» (2012) повесте Г. Вафин иҗатын яңа баскычка күтәрде [Хәлиуллина, 2012].

Шулай итеп, язучылар тарафыннан тәкъдим ителгән хикәя һәм повестьларда иҗтимагый мәсьәләләр, тирәлек һәм шәхес мөнәсәбәтләре, тәрбия-әхлак, кеше язмышы проблемалары киң чагылыш таба. Шул ук вакытта кайбер әдәби жанрларның, мәсәлән, фантастик әсәрләрнең бөтенләй диярлек очрамавын, детектив яки мәхәббәт романнарының сирәклеген билгеләргә кирәк [Хәлиуллина, Сөләйманова, 2015, б. 11]. Хәзерге көндә әдәбиятка килгән яшь язучылардан Айдар Басыйров, Аида Хәйретдинова, Гөл Мирһади, Эльмира Ибраһимова, Дилә Мөхәррәмова, Венера Мәҗитова каләме өметле күренә.

Хәзерге вакытта иҗат активлыгы белән аерылып торган төрле буын һәм төрле стиль язучылары иҗатына кыскача күзәтү ясаганнан соң, Башкортстанда татар телендә тудырылган әдәби әсәрләр җыелмасы, төбәк әдәбияты кысаларында гына калмыйча, гомумтатар сүз сәнгатенең зур казанышы булып тора дигән нәтиҗә ясарга мөмкин. Төбәк татар прозасы, уртак сыйфатлар белән беррәттән, үзенчәлекле тенденцияләр белән дә характерлана. Тулаем алганда, Башкортстандагы татар телендә иҗат ителгән тезмә һәм чәчмә әсәрләр гомумтатар сүз сәнгате үсешенә үз өлешен кертерлек, еллар сынавын кичәрлек кимәлдә. Татар әдәбиятының казанышы саналырлык әдипләребез иҗат мәйданында тынгысыз хезмәтен дәвам итә, алмашка өметле каләмдәшләре үсә дип әйтергә ныклы җирлек бар.

**Әдәбият**


Әдәбият белеме: терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге. Казан: Мәгариф, 2007. 231 б.

Әнгам Атнабай. «Бу җирне мин матурларга тудым»: Халык шагыйре хакында замандашлары. Төз. Р. Ханнанов. Уфа: Китап, 2003. 269 б.

*Заһидуллина Д.* Уңай герой югалу: сәбәпләр, нәтиҗәләр // Казан утлары. 2004. № 10. Б. 134–144.

*Заһидуллина Д.* Яңа дулкында (1980-2000 еллар татар прозасында традицияләр һәм яңачалык). Казан: Мәгариф, 2006. 255 б.

*Заһидуллина Д.* Яшьләрдә яңалык бар! («Идел» журналында дөнья күргән яшь иҗатчыларның әсәрләренә бер караш) // Идел. 2010. № 12. Б. 54–57.

*Заһидуллина Д. Ф.* Татар әдәбияты: Теория. Тарих / Д. Ф. Заһидуллина, Ә. М. Закирҗанов, Т. Ш. Гыйлаҗев, Н. М. Йосыпова. Казан: Мәгариф, 2006. 319 б.

*Кәбиров М.* Әдәбиятыбыз бәхетенә булсын // Тулпар. 2009. №6. Б. 20–21.

*Кәрим Кара.* Без әнкәй йөрәгеннән чыктык. Повестьлар, хикәяләр. Уфа: Китап, 2009. 304 б.

*Кәшфи Л.* «Кызыл таң» һәм заман әдәбияты. Уфа: «Кызыл таң» басмаханәсе, 2014. 296 б.

*Латыйфи Ф.* 2002 нче ел прозасына бер караш // Казан утлары. 2003. № 5. Б. 135–140.

*Миңнуллин Р.* «Башкортстанда үзгә бер көчле татар әдәбияты үсеп килә» // Кызыл таң. 2006. 7 декабрь.

*Морзакаева Д.* Милли китап: Зәйнәп Биишева исемендәге Башкортстан «Китап» нәшриятында милли басмалар нәшерләү һәм биредә дөнья күргән китаплар хакында. Уфа, 2012. 152 б.

*Сафуанов С.* Рухи күперләр. Уфа: Китап, 2006. 376 б.

*Сәгыйдуллина Л.* Сары йортлар сере (М. Кәбировның «Сары йортлар сере» әсәренә бер караш) // Тулпар. 2004. № 1. Б. 48–50.

*Сөләйманов Р.* Башкортстан татар прозасында кырыс реализм чалымнары // Гуманистическое наследие просветителей в культуре и образовании: материалы Международной научно-практической конференции, приуроченной к 180-летию со дня рождения М. Акмуллы, 16 декабря 2011 г. Уфа: Издательство БГПУ, 2011. Б. 235–241.

*Сөләйманов Р.* Кешеләр илендәниләр бар? // Башҡортостан уҡытыусыһы. 2014. №4. Б. 49–53.

*Фазлетдинов И. К.* Тәнкыйтьтә Башкортстандагы хәзерге татар поэзиясе // Татарика. 2016. № 2 (7). Б. 64–78.

*Фәтхерахманов Р.* Татарга сатма матбугат // Казан утлары. 2004. № 3. Б. 142–149.

*Хафизов С.* Авыл яшьләре турында заманча әсәр // Кызыл таң. 2010. 3 ноябрь.

*Хафизов С.* Шагыйрьлеккә дәгъва итүләре Ходай белән тиңләү үзеңне: яшьләр прозасында ниләр бар? // Кызыл таң. 2007. 15 ноябрь.

*Хәлиуллина А.* Бабайчылык сәбәпләре нидә? // Тулпар. 2012. № 5. Б. 28–29.

*Хәлиуллина А.* К.Кара прозасында төп мотивлар // Гуманистическое наследие просветителей в культуре и образовании. Материалы Международной научно-практической конференции, приуроченной к 180-летию со дня рождения М.Акмуллы. (Уфа, 16 декабря 2011 г.). Уфа: изд-во БГПУ, 2011. Б. 260–264.

*Хәлиуллина А.* М. Кәбиров повестьларында афористик фикер бирелеше // Система непрырывного образования: школа-педколледж-вуз. Материалы региональной научно-практической конференци, посвященной 125-летию со дня рождения Г.Тукая (Уфа, 21 апреля 2011 г.). Уфа: Изд-во БГПУ, 2011. Б. 154–156.

*Хәлиуллина А.* Маҗаралы юлның хикмәте // Исмәгыйлев Х. Зимагурлар: повесть. Уфа: Китап, 2013. Б. 3–6.

*Хәлиуллина А.* Һәр заманның үз җыры // Балкыш. Төз. Д. Д. Сөләйманова, А.Г.Хәлиуллина. Уфа: Мир печати. 2016. Б. 6–33.

*Хәлиуллина А.* Хикәя нидән гыйбарәт? //Тулпар. 2009. № 1. Б. 34–36.

*Хәлиуллина А.* Чиләккә йолдыз җыеп (Дилбәр Булатова хикәяләрендә герой эволюциясе) // Тулпар. 2011. № 1. Б. 36–37.

*Хәлиуллина А., Сөләйманова Д.* Илһам алып туган туфрактан // Тулпар. 2015. № 4. Б. 28–31.

*Хәлиуллина А., Сөләйманова Д.* Туган як әдипләре. Башкортстанда хәзерге татар прозасы: шәхес, иҗат, тәнкыйть. Уфа: Китап, 2013. 320 б.

*Хәлиуллина А. Г.* Заман һәм герой (хәзерге татар прозасында әдәби геройны гәүдәләндерү мәсьәләләре). Монография. Уфа: БДПУ нәшр-ты, 2007. 206 б.

*Гилазов Т. Ш.* Вклад Джамала Валиди в историю татарской литературной мысли // Филология и культура. 2015. № 4 (42). С. 206-209.

*Халиуллина А.Г.* Региональные особенности современной татарской прозы Башкортостана // Национальная литература республик Поволжья: проблемы межкультурной коммуникации: материалы Межрегиональной научно-практической конференции (Казань, 21–22 ноября 2016 года). Казань: изд-во Казан. ун-та, 2016. С. 157–161.

*Юзмухаметова Л. Н.* Новые явления в татарской прозе рубежа XX–XXI веков: постмодернизм. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2016. 220 с.

*Yusupov A. V., Gilazov T. Sh.* The critic Jahmal Validi in the context of literary, the oretical and philosophical searches of the beginning of the XX century literature // Journal of Language and Literature, ISSN: 2078-0303, Vol. 7. No. 2. May, 2016, pp. 344–347.

---

# СОВРЕМЕННАЯ ТАТАРСКАЯ ПРОЗА В БАШКОРТОСТАНЕ: К ВОПРОСУ О СВОЕОБРАЗИИ РАЗВИТИЯ ЛИТЕРАТУРНОГО ПРОЦЕССА

**Альбина Габитовна Халиуллина,**
Башкирский государственный педагогический университет им. М. Акмуллы,
Россия, 450000, г. Уфа, ул. Октябрьской революции, д. 3 А,
ahmali76@mail.ru.

В статье на основе обзора литературных произведений конца XX – начала XXI века определены ключевые тенденции в развитии современной татарской прозы в Республике Башкортостан. Ценность и новизна исследования состоит в том, что впервые выявлено идейно-тематическое, литературно-эстетическое, жанровое, стилистическое своеобразие современной татарской прозы указанного периода. Доказано, что при художественной передаче действительности велика роль не только реалистических приемов, но и новых стилевых тенденций, доселе не встречающихся в литературе. В эпицентре внимания оказались произведения, которые до сих пор не получили достойную оценку у критиков. В статье кратко очерчены литературные портреты таких писателей, как Г. Гатауллин, Х. Мударисова, Д. Булгакова, З. Салихова, А. Закиев; отслеживаются эксперименты Т. Тагирова, С. Поварисова, А. Магазова, Р. Сабитова, Р. Ханнанова, Э. Агъзами, М. Гилазова, И. Тимерханова, Ш. Исмагилевой, в области формы и композиции; более подробно проанализировано творчество М. Кабирова, К. Кара, Х. Исмагилева, Д. Булатовой. В работе высказывается мысль о том, что творчество татарских писателей Башкортостана должно анализироваться не только в рамках региональной литературы, но и как достижение татарской национальной культуры в целом.

**Ключевые слова**: современная татарская проза, Башкортостан, региональная литература, литературный процесс, традиция, новаторство, своеобразие жанра, синкретизм.